**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТУЙМЕТКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул.Школьная, дом 4, с.Туйметкино, 423108

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90.Tuy.Cmn.2@tatar.ru

---

**25 ноябрь 2022 ел** **№ 20**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указының 4 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 декабрендәге 86 номерлы «Туймәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Туймәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә (һәм Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 маендагы 55 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), **КАРАР БИРӘМ:**

1. Биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Туймәт авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.Б. Кәримов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль
районы Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 25 ноябрендәге
20 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
   - Башкарма комитет җитәкчесе;
   - Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;